КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 май г.Казань № 426

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче; 2020 ел, 17 апрель, 299 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Инспекциянең бурычы

Инспекциянең бурычы – дәүләт төзелеш күзәтчелеге предметы кысаларында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау.»;

3.2 нче пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01);»;

3.3 нче пунктның унҗиденче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Инспекция Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра:

а) проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеше нигезендә эшләр башлану турында хәбәр алу датасыннан яраклылык турында бәяләмә бирү датасына кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза ясалырга тиешле капиталь төзелеш объектларын (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән объектлардан тыш) төзегәндә;

б) әгәр дә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне, шул исәптән мәдәни мирас объектларын (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән объектлардан тыш) саклап калу буенча күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашыруга проект документларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеше нигезендә эшләр башлану турында хәбәр алу датасыннан яраклылык турында бәяләмә бирү датасына кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза ясалырга тиеш булса, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә, шул исәптән төбәк һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча мондый объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка тасвирнамәләренә кагылышлы эшләрне башкарганда;

в) бу пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелмәгән капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, шулай ук төзелеш, реконструкция эшләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган нигезләр буенча тәмамланган капиталь төзелеш объектларына карата (әгәр дә күрсәтелгән эшләр тәмамланганнан соң объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алынган очрактан тыш).»;

4.1 нче пунктта:

4.1.1 нче пунктчада:

икенче абзацта «(дәүләт яки дәүләткә карамаган)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү барышында эшләрне башкару һәм кулланыла торган төзелеш материаллары, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы

15, $15^2$ һәм $15^3$ өлешләре нигезендә расланган проект документлары таләпләренә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы $3^8$ һәм $3^9$ өлешләре нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм (яки) мәгълүмат моделе таләпләренә (мәгълүмат моделен булдыру һәм алып бару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта), шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә (энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан тыш) һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән капиталь төзелеш объектын тәэмин итү таләпләренә туры килү;»;

түбәндәге эчтәлекле $4.1.1^1$ нче пунктча өстәргә:

«$4.1.1^1$. Бу Нигезләмәнең 3.4 нче пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән объектларга карата капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт кәгазе булу-булмауга һәм аның төзелешкә рөхсәт кәгазендә күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвенә тикшерү, ә капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү өчен төзелешкә рөхсәт кәгазе бирү таләп ителмәгән очракта, капиталь төзелеш объектлары параметрларының җирләрдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларына һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган нигезләр буенча башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килүенә тикшерү үткәрергә.»;

түбәндәге эчтәлекле $4.1.6^1$ нче пунктча өстәргә:

«$4.1.6^1$. Әгәр дә бу Нигезләмәнең 3.4 нче пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекция тарафыннан капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләүне, төзелешкә рөхсәт кәгазе алмыйча, гамәлгә ашыру факты (капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү өчен мондый рөхсәт кәгазе бирү таләп ителмәгән очраклардан тыш) яки капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәт кәгазендә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланганда, ә капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү өчен төзелешкә рөхсәт кәгазе бирү таләп ителмәгән очракта, капиталь төзелеш объектының җирләрдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларына һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килмәве факты ачыкланганда, Инспекция, тикшерү тәмамланган көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, мондый капиталь төзелеш объекты урнашу урыны буенча җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органына яки, капиталь төзелеш объекты авыл арасындагы территориядә урнашкан очракта, муниципаль районның җирле үзидарә органына, тиешле фактны раслый торган документларны теркәп, үз белдерге белән төзелгән корылманы ачыклау турында хәбәрнамә җибәрә.»;

4.1.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.7. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча актлар төзергә, алар нигезендә ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә. Бу Нигезләмәнең 3.4 нче пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларында үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирелми.»;

4.3 нче пунктка «19.4 статьясының 1 өлеше» сүзләреннән соң «, $19.4^{1}$ статья-сы» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин